# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**22 ноября 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 22 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләренә таянып, түбәндәге мәсьәлә буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I һәм II төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Түбән Тархан авылы эчендәге юлларны төзекләндерү өчен ком һәм вак таш сатып алу;
- Түбән Тархан авылында кое төзү;
- Түбән Тархан авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, ятырткычлар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру ?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 126 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 68 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 68 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлегенең Түбән Тархан торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I һәм II төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, irектән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Түбән Тархан авылы эчендәге юлларны төзекләндерү өчен ком һәм вак таш сатып алу;
- Түбән Тархан авылында кое төзү;
- Түбән Тархан авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, ятырткычлар һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру ?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

карар кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.М. Айзатуллов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тархан авыл җирлеге башлыгы** **А.М. Айзатуллов**